Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче Яңа Кармәт авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2019 елның 29 ноябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Яңа Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 нче статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советының 2019 елның 29 октябрендә кабул ителгән "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында " №98 карары нигезендә 2019 елның 29 ноябрендә "Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Яңа Кармәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 Төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары тыш, 2020 елда 500 сум куләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Яңа Кармәт авылы. Жданов, Карл Маркс, Тукай, Кызылармия, Зеленая урамнарына таш һәм ташлы грунт сатып алу;
- Яңа Кармәт авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту.

2) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- су башнясы өчен җиһазлар сатып алу;

хәл итүгә җибәрүгә юнәлдерүгә килешәсезме?

ӘЙЕ ЮК ТЫЕЛЫП КАЛДЫ" соравы буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 226 гражданин, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 150 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

- «әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 141 кеше тавыш бирде;
- «юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 9 кеше тавыш бирде.
- "тыелып калды" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче Яңа Кармәт авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре-чын.

2."Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлегенең Яңа Кармәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Яңа Кармәт т. п. Жданов, Карл Маркс, Тукай, Кызылармия, Зеленая урамнарына таш һәм ташлы грунт сатып алу;

- Яңа Кармәт авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту;

2) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- су башнясы өчен җиһазлар сатып алу;

хәл итүгә җибәрүгә юнәлдерүгә килешәсезме?"

соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Яңа Кармәт авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнашкан рәсми сайтында: http://aksubaevo.tatar.ru Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында:http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы И. Р. Шакиров

СОВЕТ НОВОКИРЕМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ